**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы**
**Чулпан авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**05 июль 2022 ел** **№ 42**

**Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Советының 2021 елның 28 июлендәге 20 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2008 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль берәмлек Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Чулпан авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Советының 2021 елның 28 июлендәге 20 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Чулпан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Советының 2022 елның 20 маендагы 39 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Нурлат муниципаль районының 2021 елның 28 июлендәге 20 номерлы Чулпан авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә, Нигезләмәнең 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«4.2. Чулпан авыл җирлеге территориясендә агач һәм куакларны кисү Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Чулпан авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан 17 эш көне дәвамында комиссия тикшерүе акты нигезендә бирелгән рөхсәт нигезендә башкарыла».

3. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Чулпан авыл җирлеге Советының сәламәтлек саклау, санитария һәм экология эше буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Чулпан авыл җирлеге Советы Рәисе Ф.Ф. Зыятдинов